6+

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы " Ямаширмә " Йолдыз" балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе

# Эш дәфтәре

# "БАЛАЛАР БАКЧАСЫНА СӘЯХӘТ"



**Кадерле әти-әниләр, апалар-абыйлар һәм тәрбиячеләр!**

**Бу эш дәфтәренең (6+) төп максаты - балаларның тәрбияче һөнәре турында күзаллауларын киңәйтү, тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү.**

**Бурычлар:**

- **балаларның тәрбияче һөнәре турындагы белемнәрен системалаштыру;**
- **татар теле орфографиясе буенча белемнәрен камилләштерү;**
- **баш миенең ярымшарларының үзара бәйләнешен үстерү;**
- **игътибарны һәм фикерләүне камилләштерү.**

# ГӨЛНАЗ АПА



Сәлам! Мин - Әминә, миңа 5 яшь. Мин "Йолдыз" исемле балалар бакчасына йөрим. Миңа анда бик ошый, чөнки көннәр бик күңелле уза. Безнең тәрбиячебезнең исеме - Гөлназ апа. Ул балаларны бик ярата, һәр иртәне безне шатланып каршы ала, кочаклый. Без дә аны яратабыз.

Тәрбияче апа безгә күп белем бирә, шигырьләр-җырлар өйрәтә, мавыктыргыч уеннар уйната һәм күңелле бәйрәмнәр оештыра.



# БЕЗНЕҢ КӨНЕБЕЗ





Тәрбияче апа безнең белән иртәнге гимнастика ясый

Тәмле ризыклар белән сыйлый







Төрле-төрле шөгыльләр үткәрә





Саф һавада безнең белән уеннар оештыра







Әкиятләр сөйләп йоклата

Кызыклы китаплар укый, уеннар уйный безнең белән

# КОЯШКАЙ

Без тәрбияче апа белән бергә үзебезнең балалар бакчасы турында шигырь өйрәнәбез. Ләкин кайбер сүзләрдә хәрефләр төшеп калган. Дөрес хәрефләрне буш урыннарга яз.

**Б_кчабызда бик күңелле,**
**Кояш балкый безнең йөздә.**
**Шатл_нышып киләбез без,**
**“Кояшкай”да рәх_т безгә.**

**Тәрби_че апаларның**
**К_яш кунган йөзләренә.**
**Алар безгә әни к__бек,**
**Утырабыз тезләренә.**

**Уйныйбыз да, ж__рлыйбыз да,**
**Спортта да сынатмыйбыз.**
**“К__яшкай”да рәх_т безгә,**
**Без берк_йчан тик ятмыйбыз.**


**Әнә шундый бик күң_лле**
**Бакч_быз бар, белегез сез.**
**Аны күр_сегез килсә**
**Бер кунакка кил_гез сез!**




**Автор - Минзифа Әхмәтшина**

# ЯҢА БАЛАЛАР


**Безнең төркемгә яңа балалар килергә тиеш, тәрбияче апага аларның исемнәрен белергә ярдәм ит. Шифр ярдәмендә буш шакмакларга хәрефләрне яз һәм исемнәрне укы.**




| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| А | Ә | И | Г | Е | С | Й | М | Л | Н | Ө | Я |




| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |




| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |




| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |



| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |




| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

НЕЙРОУЕН

# ТӘРБИЯЧЕ

Берьюлы сул кулның имән бармагы белән хәрефне, ә уң кулның имән бармагы белән - аның төсен күрсәтеп, сүзне укы.

И Ә Т



Б Ч Е Р Я



# ШӨГЫЛЬГӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

Тәрбияче апа балалар белән аппликация ясау шөгыле үткәрергә җыена. Аңа түбәндә язылган җиһазлар һәм материаллар әзерләргә кирәк. Филфордда ул сүзләрне табып сыз.

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| С | ~~К~~ | ~~Ә~~ | ~~Г~~ | ~~А~~ | ~~З~~ | ~~Ь~~ | Е | Н | Ә | Л | А |
| К | Г | И | О | К | А | Т | Ы | Р | Г | Ы | З |
| О | К | Л | Е | Ё | Н | К | А | К | Т | Ә | Л |
| Ч | Б | Г | З | Җ | И | Л | Е | М | Л | Ө | А |
| К | А | Й | Ч | Ы | А | Ж | Л | Н | Һ | Н | К |
| Ү | О | С | С | П | У | М | А | Л | А | К | К |
| П | А | И | Р | Э | Ш | Р | О | Ү | Ү | Р | Н |
| Ң | А | Т | Ө | Й | М | Ә | Л | Ә | Р | А | О |
| И | О | О | Ы | Ж | С | Р | Ш | Г | К | И | Н |
| Е | К | П | Л | А | С | Т | И | Л | И | Н | Д |
| Б | Г | Т | Е | Р | К | Ө | Й | Э | С | Н | Ә |
| И | Ң | К | Я | Ф | Р | А | К | Л | А | Р | Һ |


~~КӘГАЗЬ~~
КАТЫРГЫ
КЛЕЁНКА

КАЙЧЫ
ПУМАЛА
ЖИЛЕМ


ТӨЙМӘЛӘР
ПЛАСТИЛИН
ЯФРАКЛАР

# ЯҢА УЕНЧЫК

Төркемгә яңа уенчык алырга кирәк. Тәрбияче апага аның исемен белергә ярдәм ит - кроссвордка уенчыкларның исемнәрен яз.



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
" Ямаширмә " Йолдыз" балалар бакчасы мәктәпкәчә
муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе



Автор:
Гыйләҗиева Энҗе Рәшит кызы